**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында гражданнар җыены карары**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы гражданнары җыенының 2023 елның 14 ноябрендәге 1нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:.

“2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

-торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, Боерган авылында килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү”.

2. Җыен нәтиҗәләрен Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге башлыгы И.В.Малышева

Халык җыены секретаре О.А.Малышева